**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы**

Чубар-Абдул авылы № 138 «23» апрель 2019 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге 20.10.2017 ел №73 карары белән расланган, «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә
Чубар-Абдул авыл җирлеге Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге __.10.2017 ел №__ карары белән расланган, «Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә, 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«1. Әлеге Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чубар-Абдул авыл җирлеге __.10.2017 ел №__ карары белән расланган, « Чубар-Абдул авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәр тарафыннан коммерциячел булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу яки аларның коллегиаль идарә итү органнары составына керү өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турындагы Нигезләмә Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнде» һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан иҗтимагый оешма (сәяси партиядән тыш), торак,

торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, шәхси башкарма орган сыйфатында күчемсез милек милекчеләр ширкәте яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керү (алга таба - коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә муниципаль хезмәткәрләрнең бушлай катнашуы) белән түләүсез нигездә катнашу өчен эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу процедурасын регламентлый.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru. урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http//aznakayevo.tatar.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чубар-Абдул авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Н. Ә. Фәтхетдинов